**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет**

**Борискинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**Борис авыл жирлеге**

**Советы**

Адрес: 422883, РТ, с. Борискино, ул. Дружбы , 8
тел: 8 (84346) 76-239

Адресы: 422883, РТ, Борис авылы, Дуслык ур.,8
факс: 8 (84346) 76-239

**РЕШЕНИЕ** с.Борискино **КАРАР**

2014 елның 5 ноябре № 119

«Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 7.1 өлеше, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 18 маендагы «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 559 номерлы Әмере, Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 18 маендагы «Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, федераль дәүләт хезмәткәрләренең һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнарының рәсми сайтларында аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру тәртибен һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау турында» 561 номерлы Әмере, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге "Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 460 номерлы Әмере (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 2014

елның 23 июнендәге 460№ Әмере), Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» УП - 343 номерлы Әмере, Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта итеп бирелгәнне расларга:

«Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә (1 нче кушымта);

Гражданнарның керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, шул муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган муниципаль вазыйфалар исемлеге (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Әлеге карар аңа имза куйган көннән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Борис авыл җирлеге башлыгы Г.В.Самарина

Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советының 2014.05.11, 119№ карарына1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы«Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә түбәндәгеләрне тапшыру тәртибен билгели:

«Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре, милек хокукындагы мөлкәт һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милек хокукындагы мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр);

«Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар, керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм үз чыгымнары турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр).

2. Әлеге Нигезләмәдә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар дигәндә - муниципаль берәмлек Советының «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» карары белән расланган исемлек нигезендә (алга таба шулай ук - «Муниципаль берәмлек советы») җирле үзидарәнең сайланулы органнары депутатлары, әгъзалары, «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затлары (алга таба шулай ук - «муниципаль берәмлек») .

3. Әлеге Нигезләмә нигезендә «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм «Әлки муниципаль районының Борис

авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль берәмлектә биләүче затлар законнарда күрсәтелгән белешмәләрне тапшырмаган «Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган исемлектә каралган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра.

4. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Әмере белән расланган белешмә формасы буенча "Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге" муниципаль берәмлектә вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелгәндә (вазыйфага билгеләү, сайлану) муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар (алга таба - муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар)тарафыннан тапшырыла.

5. Әлки муниципаль районында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр "Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар (алга таба - муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар) тарафыннан "Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы карары белән расланган исемлектә каралган, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Әмере белән расланган белешмә формасы буенча ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы граждан вазыйфасы буенча вәкаләтләр биргәндә (вазыйфага билгеләнгәндә, сайланганда) тапшыра:

а) муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм граждан муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) карата мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) гражданның муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында, шулай ук мөлкәт хокукында булган мөлкәте турында һәм граждан муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) карата мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

7. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат ел саен тапшыра:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) хисап чорында алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында (балигъ булмаган балалар 1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр, хисап чорында балигъ булган балалар өчен - балигъ булу яшенә җиткәнче) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында.

8. Белешмәләр муниципаль берәмлек Советы тарафыннан вәкаләт бирелгән вазыйфаи затка тапшырыла.

9. Муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы граждан яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан тапшырган белешмәләрдә күрсәтелмәгән яисә тулысынча чагылдырылмаган яки нинди дә булса хата булган очракта, алар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

Муниципаль вазыйфаны биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга мөмкин.

10. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан объектив сәбәпләр аркасында хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр күрсәтелмәгән очракта, әлеге факт муниципаль берәмлек Советы яисә муниципаль берәмлек Советы (муниципаль берәмлек Советы йөкләмәсе буенча гамәлдә булган) карары белән төзелә торган вәкаләтләренә муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары системасында вазыйфаларны биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәве, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә хәл итү,

керемнәр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү керүче вәкаләтле комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

12. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

Әлеге белешмәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда вазыйфаи затларга бирелергә мөмкин.

13. Муниципаль вазыйфаны биләүче затның, аның хатынын (ирен) һәм балигъ булмаган балаларының, шулай ук алар исәбеннән җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, законнарда каралган тәртиптә аларны алу чыганаклары турында муниципаль берәмлекнең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, ә шушы белешмәләр булмаган очракта, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен тапшырыла.

14. Муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган белешмәләр белән эшкә вәкаләтле затлар арасыннан әлеге белешмәләрне фаш итүдә яисә законнарда каралмаган максатларда файдалануда гаепле булучылар, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне таратуда гаепле затлар законнар нигезендә җаваплы.

15. Әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук ул ел саен тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре муниципаль вазыйфаны биләүче затның шәхси эшенә беркетелә.

Әлеге Нигезләмә нигезендә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр биргән граждан муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән очракта, әлеге белешмәләр аңа башка документлар белән бергә язма гаризасы буенча кире кайтарыла.

16. Муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы граждан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып

белешмә тапшырмаган (срогын бозган) яисә ялган белешмә тапшырган очракта, муниципаль вазыйфаны биләүче зат законнар нигезендә җаваплы.

Муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан үз чыгымнары турында тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр бирелү яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында ялган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшыру законда билгеләнгән тәртиптә авзыйфасыннан азат итүне таләп итә торганхокук бозу булып тора.

Әлки муниципаль районы Борис авыл җирлеге Советының 2014.05.11, 119№ карарына 2 нче кушымта

**Гражданнарның керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Әлки муниципаль районының Борис авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, шул муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган муниципаль вазыйфалар исемлеге**

Муниципаль берәмлек Башлыгы

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле җирле үзидарә органы рәисе

Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле җирле үзидарә органы рәисе урынбасары

Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкиллекле органы депутатлары